**Татарстан Республикасы Эгерже муниципаль районы**

**ШАРШАДЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫНЫН**

**2014 нче елда авыл жирлегенен эшчэнлеге буенча отчеты.**

**Хормэтле: Валерий Владимирович! президиум, авылдашлар, жыелышта катнашучы кунаклар! Рохсэт итегез Шаршады авыл жирлегенен 2014 нче елда эшчэнлеге буенча отчет жыелышын ачык дип белдерергэ.**

Бугенге жыелышта катнашалар: Татарстан Республикасы Эгерже муниципаль районы башлыгы Валерий Владимирович Макаров, анын урынбасарлары.

Эгерже авыл хужалыгы хэм азык-толек идарэсе начальнигы Гатауллин Дилюс Гаскэр улы

Эгерже муниципаль районы прокуроры - Парамонов Сергей Геннадиевич

Район эчке эшлэр булеге начальнигы урынбасары - Кудрявцев Александр Юрьевич

Район хэрби камиссары - Галеев Илгиз Наил улы.

Район финанс-бюджет палатасы рэисе - Бадахшин Альфред Нэвит улы

Молкэт хэм жир монэсэбэтлэре палатасы рэисе - Нэбиев Флур Фэйзи улы

Район Советы депутаты, техник инвентаризация Эгерже участогы житэкчесе- Ахметшин Булат Анвэр улы

«Агро-Кама» жаваплылыгы чиклэнгэн жэмгыяте директоры-Нургаянов Ленар Фэрит улы.

Пенсия фонды идарэсе начальнигы - Бакасова Золфия Шамил кызы.

Социаль яклау идарэсе начальнигы - Рахматуллина Сания Хэсэн кызы

Кр. Бор газ участогы мастер - Могилев Михаил Николаевич

Шулай ук жыелышта авыл жирлеге Советы депутатлары, оешма житэкчелэре катнаша.

Оештыру олеше:

Жыелышны протоколлаштыру очен, секретарь сайлау кирэк булачак, каршылар булмаса, мин Вагапова Голсияр Мэсхут кызын тэкъдим итэм.

Бертавыштан Вагапова Г.М. секретарь итеп сайлана.

Жыелышка кон тэртибе буенча тубэндэге сораулар куела:

1. Авыл жирлеге башлыгынын 2014 нче елга авыл жирлеге эшчэнлеге буенча отчетын тынлау.
2. 2014 нче елга халыктан жыела торган узара салым кулэмен билгелэу.

Кон тэртибенэ остэмэлэр бармы?

Булмаса, беренче кон тэртибе буенча, сезнен рохсэт белэн, сузне уземэ алам.

Хормэтле авылдашлар хэм килгэн кунаклар!

Агымдагы тагын бер ел, 2014 нче ел утеп китте. 2014 нче елнын зур вакыйгаларынын берсе булып, 14 нче сентябрь конне узган Татарстан Республикасы Дэулэт Советына депутатлар сайлау коне белэн тарихка кереп калды. Моннан башка да 2014 нче ел дэвамында республика, район кулэмендэ зур вакыйгалар, узгэрешлэр булып узды, куп эшлэр эшлэнде лэкин аларга барысына тукталып тормыйча, узебезнен авыл жирлегенен 2014 нче елдагы эшчэнлеге белэн таныштыруга кучэм.

Турыдан-туры авыл жирлегенен 2014 ел эшчэнлеге белэн таныштыруны, 2013 нчы хэм 2014 нче елларны чагыштырып, сезне авыл жирлеге тормышына кагылышлы берникадэр цифрлар белэн таныштырып китэсе килэ. Хужалыклар санына килсэк, 2013 елда 188 хужалык булган булса, 2014 нче елда 191 хужалык булып, гомуми хужалыклар саны 3 хужалыкка арткан. Халык саны узгэрмэгэн, 408 кеше калган. Болар арасында эшкэ яраклылар 204 кеше, шулардан 156 кеше эш белэн тэимин ителгэн хэм 48 кеше эшсез . Авыл жирлеге буенча уртача хезмэт хакы 11050 сум. ( район буенча уртача 24272 сум) Пенсионерлар 120 кеше, барлык халыкнын 29 %ын тэшкил итэ. Уртача пенсия кулэме 10027 сум (район буенча уртача 9181 сум). Э барлыгы 2014 нче елда пенсионерларга 12 млн. 487 мен сум пенсия олэшенгэн. Авыл жирлеге буенча 23 пенсионерны караучыга аена 1200 сумнан компенсация тулэнеп барылган. Яшь семьяларга остэмэ социаль

ярдэм курсэту программасы аркылы 20 семья бала капиталына сертификат алган, шуларнын 14- е сертификат белэн файдаланган инде.

Авыл жирлеге буенча балалар барлыгы 84, шулардан уку яшендэгелэре 44, укугача яшьтэгелэр 40 бала. Жирлектэ 29 инвалид, 1 сугыш ветераны исэплэнэ. 2013 нче елда11 кеше улгэн булса, 14 нче елда 6 кеше улгэн, узган ел белэн чагыштырганда улучелэр саны 5 кешегэ кимрэк.13 нчы елда 6 бала туган булса, 2014 нче елда 7 бала доньяга килгэн. 2014 нче елда туучылар саны узган 2013 нче елгыдан бергэ артыграк.

Хужалыклардагы терлеклэргэ килсэк, авыл жирлеге буенча эре могезле терлеклэр саны барлыгы 54, Шаршады авылында 40 хэм Сэхрэдэ 14 баш. Моннан тыш Нурмухаметов Ирекнен семья фермасында 15 баш угез симертелэ, боларны да исэплэгэндэ, авыл жирлеге территориясендэ барлыгы 69 баш эре могезле терлек килеп чыга.

Шул ук вакытта сарык, кэжэ башы 81. Болардан 67 се сарык хэм 14 кэжэ. Бал кортларынын семьялары саны 254 башка житкэн. Шулай ук барлык хужалыклар буенча 307 баш йорт кошлары исэплэнэ.Авыл жирлеге территориясендэ шэхси хужалыкларда 11 данэ копчэкле хэм чылбырлы трактор, 2 ашлык сугу комбайны, 3 йок хэм 38 жинел машина исэплэнэ.

***Авыл жирлеге территориясендэ урнашкан оешмалар турында берничэ суз:***

**Жирлектэ Кочек урта мэктэбе филиалы эшли**. Шаршады башлангыч мэктэбе Кочек гомуми мэктэбенен филиалы булып санала, административ эшлэрне турыдан-туры Кочек мэктэбенэ карый.

Мэктэптэ 19 бала белем ала, 6 сы рус миллэтеннэн, аларга 4 укытучы белем бирэ. 3 сыйныф комплект: 2 татар сыйныфы, 1 рус сыйныфы. Кочек мэктэбе укытучылары арасыннан килеп берем биручелэр – 2. Балалар дус, тату яшилэр. Рус телле балалар татарчага ойрэнеп, татарлары русча сойлэшергэ ойрэнеп усэлэр. Балалар арасында каршылыклар булганы юк. Укытучылар барысы да махсус югары белемле, 4-се беренче категорияле. 5 укучы икенче яртыеллыкны «4» хэм «5» билгелэренэ генэ тэмамлаган.2014 нче ел ГТО нормаларын кире кайтару елы булып истэ калачак. Бала сэламэтлеге акчага сатып алып булмый торган байлык икэнлеген анлап, ата-аналар балаларына чангылар, спорт очен башка кирэк-яраклар сатып ала башладылар, бу матур куренеш. Балаларны торле ярышларда, конкурсларда катнаштыру очен дэ куп коч куялар мэктэп укытучылары.Хэзерге вакытта

зур жинугэ багышланган конкурста катнашалар хэм жинунен 70 еллыгын каршылау буенча зур эзерлек алып барыла.Унайдан эйтеп китэсе килэ. Быел, белгэнегезчэ, илебез Боек Жинунен 70 еллыгын билгелэп утэчэк. Авылыбыз жирлегендэ яшэуче бер торкем укытучылар Боек Ватан сугышында катнашкан авылдашларыбызга кагылышлы материаллар жыя башладылар хэм алга таба авылыбыз музеен булдыру хыялы белэн яшилэр. Шул унайдан, сезнен куплэп жыелуны исэпкэ алып, сезгэ шундый сорау белэн морэжэгать итэм. Сугышта катнашкан, жину белэн кайткан яки авылыбызга кире эйлэнеп кайта алмаган авылдашлар турында булган материалларны, болар: фоторэсемнэр, фронттан килгэн хатлар, яралану турында кэгазьлэр, мактау хатлары хэм башкаларны укытучы Багаутдинова Раушаниягэ биреугез сорала. Бу материаллар югалмаячак, узегезгэ кирэк дип тапканнары, кире кайтарылачак.

2014 нче елнын 25 нче маенда авыл жирлегендэ яшэуче хэм иске мэктэптэ укып белем алган куп кенэ укучылар тырышлыгы белэн, иске мэктэп бинасынын 100 еллык юбилее билгелэп утелде. Жыелган кунаклар мэктэпнен узган зур тарихы белэн  таныштырылды. Бу узган зур чарадан  кутэренке кунел белэн таралыштылар. Шунын дэвамы итеп укытучылар тарафыннан хэзерге вакытта авыл тарихы буенча эзлэну эшлэре алып барыла, материаллар эзерлэнэ. Бу материаллар шулай ук булачак музейда урын алачак.

**Балалар бакчасы.** Балалар бакчасында 2014 нче елда  барлыгы 18 бала тэрбиялэнгэн. 1яшь 6 айлыктан башлап 3 яшькэ кадэрлелэр 4 бала, 3 яшьтэн 7 яшькэ кадэрлелэр 14 бала.2014 нче ел буена барлыгы 3588 бала коне исэплэнгэн, уртача йореш 16 бала. Ата-аналардан жыела торган взнос 100 % жыепып алынган, ул 240 мен  тэшкил итэ. Бу барлык жыелган акча балаларга азык-толек продуктлары алу очен хэм башка чыгымнар очен  тотылган.

Балалар бакчасында тэрбия эшлэре еллык план буенча  алып барыла. Балалар бакчасы балалар арасында уздырыла торган торле конкурсларда катнаша, аларнын бу эштэге унышларын алынган диплом грамоталар дэлилли.Балалар белэн торле чаралар уздырыла. Мэсэлэн, 23 –февраль, 8 – Март бэйрэмнэрендэ олкэннэрне чакырып чэй остэллэре оештырылган. 9 май- Жину бэйрэме конендэ авылыбыздагы бердэн-бер сугыш ветераны Гайсин Ахмадулла абыйнын оенэ барып, узлэренен куллары белэн ясалган булэклэр тапшырып,концерт номерлары курсэтеп кайтканнар хэм башкалар. Балалар хэрвакыт медицина хезмэткэрлэре кузэтуе астында.

**<u>Фельдшер-акушерлык пункты</u>** . Фельдшер-акушерлык пунктынын топ эше- авыруларга табибка кадэр медицина ярдэме курсэту, профилактик, санитар-эпидимиолог чаралар уткэру, профилактик прививкалар ясау, авыл жирлеге территориясендэ яшэуче  барлык кешелэргэ диспансеризация уздыру хэм башкалар.Фельдшер- акушерлык пункты карамагында барлыгы 408 кеше шулардан 1 яшькэчэ балалар -6, 17 яшькэчэ 88 бала. Бугенге конгэ 2 йокле хатын исэпкэ алынган. 2013 нче елнын июнь аеннан башлап фельдшер-акушерлык пункты хэзерге медицина оешмаларынын ботен талэплэренэ жавап бирэ торган яна бинада эшли. Ел буена  ФАП тарафыннан 4361 кешегэ кузэту уздырылган, шунын 896 сы ойлэргэ йореп.

Сонгы елларда халыкка диспансеризация уздыру эше ныклы контрольгэ куелды.2014 нче елда бу эш буенча безнен жирлектэн 50 кешенен диспансеризация узуы план итеп билгелэнгэн хэм ул 100% ка утэлгэн. Зур игътибар катын-кызларга, балаларга бирелэ. Шулай ук пенсионер авылдашлар да  бу эштэн читтэ калмый. Диспансеризация эше 2015 нче елда да дэвам итэчэк, безнен жирлектэ бу категория кешелэр саны 53. Узган 2014 нче елда бу эш сонрак башлану сэбэпле авырырак барган булса, быел ел башыннан ук фельдшер Ахметшина Гольфия Анваровна эшне башлап жибэрде, бугенге конгэ 53 кешенен 36 сы 1 нче этапны узып бетергэн инде. Хэм инде авылыбыз фельдшерынын актив эш башлавын исэпкэ алып, авыл халкынын актив катнашуына ышанып, ел барышында бу эшне авыл жирлеклэре арасында алдынгылардан булып тогэллэрбез дигэн ометтэ калабыз. Моннан тыш бер рэттэн халыкка АДС. М прививкалары ясау эше дэ алып барыла. Фельдшер-акушерлык пунктынын эше кэнэгатьлэнерлек дип эйтэ алам. Шунысы да соенечле 2014 нче елда авыл жирлегендэ туберкулез белэн авыручылар да булмаган. Бу шулай ук фельдшернын унай эш нэтижэсе.

**<u>Шаршады авыл клубы</u>** . 2014 нче авыл клубында 115 торле чаралар уздырылган, шуларнын 98-е яшьлэр очен дискотекалар, 17-се барлык авыл халкы катнашында узган чаралар. Болардан «23 нче февраль-Ватанны саклаучылар коне», «8-Март Халыкара хатын-кызлар коне», «1-апрель-колке коне», «1- Май – яз бэйрэме», «9-Май – Жину бэйрэме», татар халкынын милли бэйрэме-«Сабантуй», олкэннэр коне, энилэр бэйрэме, инвалидлар коне, Яна ел кичэсе хэм башкалар.

2014 нче елнын февраль аенда Кочек мэдэният сараенда булып узган «Мэдэни салават купере» дип аталган бэйгедэ катнашып, клубыбызнын Сандугач» коллективы 3 нче урынны алып кайтты. Шулай ук хатын-кызлар

вокалы арасында Вахитова Фируза 1 нче урынны, гармунчылар арасында «Ин шэп гармунчы» исемен Закиров Илсур абый яулады.

Моннан тыш клубта «Сэламэтлек-зур байлык», «Сэхнэбез осталары», «Белешмэлэр», «Гузэл минем туган авылым», «Терроризму-нет», «2014 нче ел- мэдэният елы» темаларына стендлар ясалды.

Бэйрэм концертларыннан жыелган акчага татар хатын-кызларынын 2 милли кулмэге тегелде.

**Авылда почта элемтэ булеге эшли .**Алар тарафыннан халыкка куп торле хезмэт курсэтелэ: 2014 елда 4628 данэ торле товарлар, конверт-маркалар сатылган. 250 данэ кредит хэм акча переводлары алынган хэм 32 акча переводы озатылган. 11 данэ посылка, бандероль кабул ителгэн. Халыктан тотылган газ ,электр энергиясе хэм йорт телефоннары очен 4452 кешедэн акча алынган. Болардан тыш кэрэзле телефоннарга акча салу , балалар бакчасы очен тулэулэр, юл кагыйдэлэрен бозуга тулэнэ торган штрафлар, банкларга кредитлар тулэу алар аша уза.

**Авыл жирлеге территориясендэ 4 кибет эшли** 2 се Эгерже РайПО сы кибетлэре, Сэхрэ хэм Шаршады авылларында. Шэхси кибетлэр 2 , алар икесе дэ Шаршады авылында. Болардан тыш тагын бер шэхси кибет тозелэ. Озакламый бу кибет тэ ачылыр дип котэбез. РайПО системасы кибетлэренен еллык товар эйлэнеше авыл жирлеге буенча 4 мил.118 мен. Аерым алганда Шаршады кибете буенча 2мил. 755 мен, Сэхрэ кибете буенча 1мил.364 мен. Сатучыларнын уртача хезмэт хакы 9833 сум.

Авылда 0,5 ставкага, ягъни 3 сэгать эш коне белэн **авыл китапханэсе эшли.** Китапханэгэ 2014 нче ел дэвамында 251 кеше язылган, шулардан 85 –е мэктэп яшендэге балалар. Ел буена 3162 китап укукчылар кабул иткэн, аларга 6335 китап куллануга тапшырылган. Китап укучылар очен 257 яна китаплар кайтартылган, шуларнын 75-е балалар очен. Яна кайткан китаплар белэн кургэзмэлэр ясалган. Китапханэ мэктэп укучылары, балалар бакчасына йоруче балалар белэн тыгыз элемтэдэ эшли. Мэктэп укучылары очен дин хэм эхлак темасына сойлэшулэр уздырылган, алар ярдэме белэн таушалган китаплар тозеклэндерелгэн хэм башка чаралар эшлэнгэн. 12 нче ноябрь конне беренче сыйныф укучыларын китапханэ кунакта кабул иткэн. Аларга беренче сыйныфнын мэдэни кондэлеге тапшырылган. Бу кондэлек белэн эш алып барылган хэм ул 2015 нче елнын май аена кадэр дэвам итэчэк.

**2014 нче елга авыл жирлеге бюджеты утэлеше**

**<u>Бюджет буенча керем ягына</u>** килгэндэ тубэндэгелэрне эйтергэ момкин: 2014 нче елга барлык керем буенча 1 мил. 549 мен 500 сум план булган булса, ел дэвамында ул 1 мил. 895 мен 900 сумга, ягъни 122 % ка утэлгэн.

Шунын эчендэ салымнар буенча 400 мен план булып, 430 мен 500 сум жыеп алынып, 108% утэлеш тэшкил иткэн. Жир салымы 75 мен планга карата 119 мен 900 сумга утэлгэн 160 %, подоходный налог 260 мен карата, 236 мен 600 сумга утэлгэн хэм утэлеш 91 %. Милек салымы 47 мен планга карата 56 мен сум утэлгэн, 119% . Налоглардан тыш керемнэр 12 мен урынына 15 мен 300 сумга утэлгэн.

**<u>Бюджеттан тыш керемнэр</u>**:

Тулэуле чаралар очен 2800 сум план каралган булса, тулысы белэн 100 % жыеп алынган. Халыктан узара салым, хэр кеше башына 100 сум исэбеннэн, 29 мен 100 сум акча жыелган. Су очен 50 мен сум планга карата 105 мен 700 сум акча жыеп алынган.

Болардан тыш госпошлина 6 мен жыелырга тиеш булган булса, 2 мен 700 сум жыеп алынып, 45 % ка гына утэлгэн. Аренда очен 5 мен план урынына 30234 сум акча жыелган, бу курсэткеч 604 %. Единый сельскохозяйственный налог 2 мен планга карата 5420 сумга утэлгэн, утэлеш 271 %. Авыл жирлегенен уз керемнэре белэн уз эшчэнлеген тээмин иту дэрэжэсе 30,1 %. Бу курсэткеч районддагы авыл жирлеклэре арасында уртача 35,8 %.

Авыл жирлегенен керемнэр буенча еллык план утэлеше 103 %. Жирлектэ яшэуче хэр кеше башына 1392 сум акча жыелган. Бу курсэткеч район буенча уртача 1300 сум.

**<u>Авыл жирлегенен гомуми чыгымнары</u>** ягына килгэндэ, чыгымнар барысы 1мил 884 мен 900 сум. Чыгымнар буенча аерым алганда: оешмалардагы тотылган электроэнергия очен 6 мен 900 сум, элемтэ очен 7 мен 700 сум, урам утларын яндыру очен 52 мен 400 сум, биналарны жылыту очен 90 мен 700сум. Су очен тотылган чыгымнарга килсэк, ул 120400 сум. Болар: су башняларында тотылган электр энергиясе очен 90 600 сум, 17100 сумга Сэхрэ авылы очен су насосы алынган хэм су суыртучыларга 12700 сум кулэмендэ хезмэт хакы тулэнгэн. Ел башыннан халыктан, кулланган су очен 105700 сум акча жыеп банкка тапшырылган. Су очен тотылган чыгым керемгэ караганда 14700 сумга артыграк. Территориядэ яшэуче хэр кеше

башына чыккан чыгымнарны алсак, бу 4620 сум тэшкил итэ. Бу курсэткеч район буенча 3631 сум.

Алдагы еллардагыча, язгы айларда авыл жирлеге, район буенча билгелэнгэн, чисталык икеайлыгында катнашты: йорт каршыларында, оешма тирэлэрендэ, урамнарда чуп улэннэрне чабу, урамнардагы, юл буйларындагы чуплэрне жыю, урамда йорт каршыларында торырга тиеш булмаган артык эйберлэрне алу кебек эшлэр башкарылды. Бу эшлэр жэйге чорда да дэвам ителде. Урамнардагы электр чылбыры баганаларынын топлэре агартылды. Авылнын чуплек территориясе трактор белэн эттереп чистартылды. Халыкнын тиеш булмаган урынга тугелгэн чуп урыннары шулай ук трактор ярдэмендэ, эттереп юк ителде.

Билгеле, 2014 нче елда авыл жирлеклэрен финанслау  башка еллар белэн чагыштырмача купкэ аз хэм авыр барды. Шулай булуга карамастан,торле момкинлеклэр табып, авыл жирлегендэ  тубэндэге эшлэрне эшлэугэ ирешелде: май аенда, остэмэ материаллар алынып, Сэхрэ авылы зиraты коймасынын тотылып бетмэгэн олеше  тотып бетерелде. Материал алу очен мэчеттэн бирелгэн хэм авыл халкыннан жыелган акчалар тотылды. Башкарылган эшлэр авылнын ир-егетлэре тарафыннан омэ формасында эшлэнде. Хэтта Сэхрэ авылында туып, читтэ яшэуче авыл егетлэре дэ кайтып катнашты бу омэдэ. Моннан башка омэ формасында су башнясына су кутэрэ торган торба  озайтылып, башнянын югары олешенэ кадэр кутэреп беркетелде. Бу эш  очен Эгерждэн «Жилэнергосерфис» оешмасыннан кран сорап алынды. Шулай ук зиярат территориялэре чуп  улэннэрдэн чабып чистартылды. Хэм эйтергэ кирэк, жыелыш алдыннан гына авылнын имамы белэн 2015 нче елга Сэхрэ зияраты буенча яна эш тэ планлаштырылды. Яз башында материаллар алып кайтып, зияраттагы коралларны, артык материалларны  тота торган  сарайны ремонтлау яки янадан житкеру. Бу турыда авылнын олкэннэре, ир-атлары белэн остэмэ сойлэшеп алачакбыз. Шулай ук Сэхрэ авылында бик начар хэлдэге 6 данэ электр баганалары алыштырылды. Унайдан шуны эйтеп китэргэ кирэк, 2015 нче елга Сэхрэ авылындагы баганаларны алыштыру хэм яна электр чыбыклары тарту капиталь ремон уздыру итеп кертелгэн

2013 елгы отчет жыелышында искэ алынып кителгэн янгын сундеру очен эзерлэнэ торган су ёмкосте эшкэ яраклandырылды. Бу ёмъкость, янгын булган очракта,  янгын сундеру машиналары килеп житкэнче кулланып тору очен, узебезнен янгын сундеру чарасы булып торачак. Бу эшне эшлэудэ авыл

жирлеге бюджетыннан бер тиен дэ акча тотылмады, барысы да узебезнен коч белэн эшлэнде.

Тагын бер суга кагылышлы мэсьэлэгэ тукталып, шуны да эйтеп китэсе килэ. Безнен арада барысын да остэн кемдер эшлэгэнне котеп ятмаган авылдашлар да бар, шунысы соенечле. Узган елнын жэй аенда, уз инициативалары белэн, Зайнутдинов урамында яшэуче Вагапов Зофэр, Хайрутдинов Алик, Ахметзянов Захит, Нургалиев Энвэр абыйлар урамдагы колонка остенэ ясалган будканы сутеп, янартып эшлэп куйдылар. Шундый ук эшне «Урманчылар» урамында Гайнуллин Ильдар узлэренен йортлары каршындагы колонкада башкарды. Шушы башкарган эшлэре очен бу иптэшлэргэ авылдашлары, шулай ук авыл жирлеге исеменнэн зур рэхмэт белдереп, тормышларында унышлар, саулык-сэламэтлек телисе килэ.

Инде 2014 нче елда мэктэп-балалар бакчасы бинасы тозелэ башлый дип котсэк тэ, жэйге чорда, балалар бакчасына йоруче балаларнын ата-аналары коче белэн балалар бакчасы бинасында вак ремон эшлэре башкарылды: бинанын тубэсендэге ватык шиферлар алыштырылды, тубэдэ моржа тирэлэре ныгытылды, идэн астындагы начар хэлдэге орлеклэр астына хэм тушэмнен начар урыннарына остэмэ терэулэр куелды хэм башка вак эшлэр башкарылды. Бу бинага сонгы тапкыр ремонт эшлэре эшлэнде дип эйтергэ кирэк,чонки барыбыз белэн дэ котеп алынган мэктэп бинасы тозелеше башланды инде хэм ул бик матур гына тозелеп килэ, бу елнын июль аена тозелеп, кулланышка тапшырылырга тиеш. 2015-2016 нчы уку елын укучы балалар хэм кечкенэлэр яна бинада башларлар дип котеп калабыз. Унайдан файдаланып, бу эшнен башында торган, бинаны житкерэ башлауга куп коч куйган Эгерже муниципаль районы башлыгы Валерий Владимирович Макаровка, анын янэшэсендэ эшлэучелэргэ авыл халкы, балаларнын ата-аналары исеменнэн зур рэхмэт белдереп, аларга унышлар, сэламэтлек, жан тынычлыгы телэп калырга рохсэт итегез.

Авыл жирлегенен 2013 нче елга ясалган отчетында Гайсина Кэримэ гаилэсе узлэренен йортлары каршына килэ торган юлны тозэттеру турында сораган иде. Аларнын сораулары утэлде, 14800 сумлык чыгым тотылып, капка каршыларына килерлек итеп юл эшлэнде. «Агрохимсервис» оешмасы машиналары, китерелгэн материаллары белэн бергэ, 11000 сумлык эш башкарды. Китерелгэн материалны таратып тигезлэу очен «Брус» оешмасынын чылбырлы тракторы 3800 сумлык эш эшлэде.

29 нчы июнь конне узара салым акчасын куллану буенча авыл халкы арасында референдум уздырылган иде, нэтижэдэ 18 яшьтэн узган, авыл жирлеге территориясендэ яшэуче хэр кешедэн 100 сум узара салым акчасы жыярга дип тавыш бирелде. Шунын нигезендэ, авыл жирлеге буенча 291 кешегэ 29100 сум акча тупланды. Шушы сумманы дуртлэтэ арттырып 116400 сум акчаны республика бюджетыннан биру вэгъдэ ителде. Халыктан жыелган 29100 сумга хэм республикадан бирелгэн остэмэ 116400 сумга, тулысы белэн 145500 сумлык «Зайнутдинов» хэм «Урманчылар» урамнарында урам юлынын начар олешлэренэ известьковый гравий кайтарып таратылды. Кызганыч, бу эшнен ни дэрэжэдэ авыл очен, авыл халкы очен кирэкле хэм файдалы эш икэнен анламаган кешелэр бар безнен арада. Алга таба да дэулэттэн мондый ярдэмнэр булып торсын хэм без аларнын тиешлесен алып, авыл очен, халык конкурешен яхшырту очен куллансак иде. Ни очен дигэндэ, бу елнын 22 мартында 2015 нче елда жыелачак узара салымны жыю хэм куллану буенча референдум уздырылачак. Узган елдагыча, дэулэт бу сумманы 4 тапкыр артырып бируне вэгъдэ итэ. 2015нче елга узара салым кулэме районнын барлык жирлеклэрендэ дэ 200 сумнан жыярга дип каралды.2015 нче елнын 1 нче январеннэн бу узара салым суммасын юллар тозэтугэ тотарга ярамау сэбэпле, без аны урамдагы колонкаларга беседкалар ясап куярга хэм буа янында янгын сундеру машиналары су тутыртып алу очен урын эзерлэтергэ дип планлаштыра идек. Сездэ нинди фикерлэр булыр, доклад азагында бу сорауга кире эйлэнеп кайтырбыз эле.

Илебездэ жирле узидарэ оештырунын топ принципларын билгели торган 131 нче Федераль законны узгэрту нигезендэ, башта авыл жирлеклэренэ тапшырылган 39 вэкалэттэн 15 генэ мэжбури кала. Калганнары муниципаль районнар карамагына тапшырыла. Болар эчендэ шул ук авыллардагы юллар, су да бар. Юллар тозэтугэ узара салым акчасын тотарга ярамау да шунан килеп чыга. Хэм шулай ук авыллардагы су буенча эшлэнэ торган эшлэр дэ бу эш белэн мостэкыйль шогеллэнуче оешмаларга бирелу турында суз алып барыла.

Сонгы елларда дисэк дорес булыр, районда административ комиссия ныклап эшли башлады. Бу комиссия, узенен тозелгэн эш планы нигезендэ, авыл жирлеклэренэ килеп утырышлар уздыра . Безнен авыл жирлегендэ бу эш апрель аена планлаштырыла. Комиссия килеп утырыш кына уздырып калмый, урамнар буенча йореп, булган кимчелеклэр очен штрафларын да салып китэчэк. Бу эш нинди тэртиптэ эшлэнгэнен сез район газетасы

битлэреннэн укып белэсез. Кимчелеклэр нэрсэлэр сон алар, бу йорт каршылырында калдырылган машина хэм башка техникалар, тозелеш материаллары, утын яки башка калдыклар, тугелгэн чуплэр, жэйге чорда улэне чабылмаган йорт каршылары, урамда караучысыз йори торган мал-туар,хужасыз этлэр хэм башкалар. Комиссиягэ Татарстан Республикасынын административ кагыйдэлэрне бозу буенча Кодексынын 4 статьясы буенча,болар 2.6 нчы ст. «Авыл жирлегенен муниципаль актларын утэмэу», 3.2 нче ст. «Урамда сату тэртиплэрен бозу», 3.4 нче ст. « Урам утларын тоту кагыйдэлэрен бозу» хэм инде 4 нчесе 3.6 нчы ст. «Авыл жирлегенен территорияне тэртиптэ саклау хэм чуплэр, калдыклар белэн эш иту кагыйдэлэрен бозу». Санап кителгэн статьялар буенча протоколлар тозелеп административ комиссиягэ тапшырылачак. Моннан тыш административ кодекснын 5 статьясы буенча протоколлар мировой судка бирелэчэк. Болар арасында 3.7 нче ст. «Этлэрне тоту кадыйлэрен бозу» да бар. Жыелыш алдыннан этлэре булган хужаларнын урамда йоруче этлэрен чылбырга куюын сорап белдеру эленгэн иде. Тагын беркат жыелышта кисэтергэ булдык. Алдан ук кисэту дип кабул итегез,без белмэдек диярлек булмасын, алга таба кадыйдэлэр бозу буенча протоколлар тозелеп тиешле урыннарга жибэрелэчэк.

Эшлэнгэн эшлэр белэн рэттэн 2015 нче елда эшлэнэсе эшлэр дэ бар эле, болар:

1.Сэхрэ авылында электр линияларын янартуны тогэллэу.

2.Башлангыч мэктэп яна бинага кучкэннэн сон, хэзерге мэктэп бинасын авыл жирлеге балансына кучереп булган очракта, бу бинаны узгэртеп, янгын сундеру машинасы алу момкинлеген табып, шушы бинага янгын сундеру машинасын урнаштыру.

3.Сонны елларда чишмэгэ йоручелэр саны артканнан- арта баруны исэпкэ алып, чишмэгэ бара торган юлны тозэту.

4.Узара салым акчасына су колонкаларына беседкалар хэм буага янгын сундеру машиналарына су тутырып алу очен урын, ягъни янгын сундеручелэр телендэ «пирс» эшлэтеп кую.

Чыгыш тэмам, игътибарыгыз очен рэхмэт.

Э хэзер инде узара салым бэясенэ кире эйлэнеп кайтабыз. Кемнэрдэ нинди фикерлэр булыр?

Йомгаклау очен сузне Эгерже муниципаль районы башлыгы Макаров Валерий Владимировичка бирэм.

Кемнэрдэ нинди сораулар бар?

Хормэтле авылдашлар,килгэн кунаклар, жыелышта катнашуыгыз очен рэхмэт!